ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ Олы МемиАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.01.2016 с. Большие Меми 1

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 431 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү эше барышында Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башлыгының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен тәкъдимнәр бирергә;

2. Җирлек Советының, җирлек башлыгының һәм җирлек башкарма

комитетының муниципаль норматив хокукый актларын, шулай ук регистрга кертелергә тиешле белешмәләрен район Советына җибәрүе өчен җаваплы итеп җирлек башкарма комитеты секретарен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова